# КАРАР
Татарстан Республикасы Азнакай район Советы

Азнакай шәһәре № 239-34 «15» февраль 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2012 елның 28 апрелендәге 139-20 номерлы карары белән расланган «Өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында», өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында (22.10.2013 ел, № 274-37, 2017 елның 9 ноябрендәге 147-22, 12.11.2018 ел, №211-31 карарлар редакциясендә)

2018 елның 13 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясына үзгәрешләр кертү сәбәпле, шулай ук Татарстан Республикасы Азнакай шәһәр прокуратурасының 2018 елның 5 декабрендәге 02-08-02/1400-2018 номерлы протестын исәпкә алып,
Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2012 елның 28 апрелендәге «Өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында» 139-20 номерлы карары (2013 елның 22 октябрендәге 274-37 номерлы, 2017 елның 9 ноябрендәге 147-22 номерлы, 2018 елның 12 ноябрендәге 211-31 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган Өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Вәкаләтле орган әлеге Кодексның 32 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлекләре бирү белән кызыксынучы гражданнарны исемлектән төшереп калдыру һәм аларга җир кишәрлеге бирүдән баш тарту турында Карар кабул итә:

1) гражданнарга әлеге Кодексның 32 статьясындагы 3 пункты нигезендә дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеге түләүсез бирү;

2) гражданнарның әлеге Кодексның 32 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве аркасында:

а) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу;

б) Татарстан Республикасы чигеннән даими яшәү урынына чыгу;

в) ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, уллыкка алынуны гамәлдән чыгару, опека яки попечительлек туктатылу;

г) ата- законсыз гамәлләре (эшләмәве) нәтиҗәсендә бала (балаларның) үлеме;

3) гражданнарның аларны исемлектән төшереп калдыру турында турында гариза бирүе;

4) җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында гражданнарның өч тапкыр кире кагуы яисә җир кишәрлеген сайлау процедурасын өч тапкыр кире кагу;

5) гражданнар исемлегенә кертелгән документларда күрсәтелгән мәгълүматның әлеге Кодексның 32 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәвен ачыклау.

Гражданнарны исемлекләрдән төшереп калдыру һәм аларга җир кишәрлеге бирүдән баш тарту турында белдерү вәкаләтле орган тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән 7 көннән дә соңга калмыйча заказлы хат белән тапшыру турында хәбәрнамә белән яисә имза куеп извещение тапшыру юлы белән гамәлгә ашырыла».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakayevo.tatarstan.ru. урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Председатель М.З.Шәйдуллин